7.2. Конференция ике этапта үтә:

- 2014 елның 14 февраленә кадәр конференция читтән торып үтә – килгән эшләр тикшерелә.
- Икенче этапка узган укытучылар 2014 елның 21 нче февральдә 8.00 сәгатькә Азнакай шәһәренең Балалар иҗат йортына (**Азнакай шәһәре, Ленин урамы, 18 нче йорт**) фәнни-гамәли конференциясенең финалына чакырыла. Алар секцияләрдә чыгышлар ясый. Фәнни-эзләнү эшләренең кәгазь варианты чыгыш ясар алдыннан экспертлар комиссиясенә тапшырыла.

7.3. Конференциядә катнашу өчен 2014 елның 14 февраленә кадәр фәнни эшне (miraskonf@mail.ru) адресына җибәрергә кирәк. (Хәбәрләшү өчен тел.: 8(843) 222-09-83 (17-91) баш мөхәррир Ләбиб Лерон; 89520365448 – бүлек мөхәррире Ленар Гобәйдуллин; 89093088105 – Сиринә Трофимова

7.4. Килгән эшләрне оештыру комитеты составына кергән экспертлар тикшергәннән соң, икенче этапта катнашу өчен **2014 елның 19 нчы февраленә** кадәр чакыру хатлары җибәрелә.

7.5. Ике кешедән торган авторларның да эшләре кабул ителә ала.

8. Бәяләү критерийлары

Казан федераль университеты Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге; "ТАТМЕДИА" ААҖ "Чын мирас" журналы редакциясе хезмәткәрләре укытучыларның фәнни эшләрен, чыгышларын түбәндәге критерийлардан чыгып бәяләячәк:

- сайланган теманың актуаль булуы;
- проблеманы чишүнең тирәнлеге, тулылыгы, үзенчәлекле ысуллары кулланылган булуы;
- фәнни эштә логик эзлеклелек саклану;
- кулланылган әдәбиятның сыйфаты;
- авторның мөстәкыйльлек дәрәҗәсе;
- чыгышның композицион бөтенлеге, дәлилли белү, теманы ача белү дәрәҗәсе;
- чыгышны күрсәтмә материал белән баету;
- чыгыш ясаучының сөйләм, аралашу культурасы;
- жюри биргән сорауларга җавапларның сыйфаты.

Экспертлар һәр юнәлеш буенча бәя бирү критерийларын конкретлаштыру хокукына ия.

Чыгыш ясау өчен укытучыга 5-7 минут вакыт бирелә. Шул вакыт эчендә укытучы төп фикерләрне кыска һәм төгәл итеп җиткерә белергә тиеш.

9. Катнашучыларны бүләкләү

- 1, 2 нче этапта катнашкан барлык укытучыларга да сертификат тапшырыла.
- Җиңүчеләр һәм призлы урын яулаучылар "ТАТМЕДИА" ААҖ "Чын мирас" журналы дипломнары белән бүләкләнә.
- Иң яхшы дип саналган эшләр **"Чын мирас"** журналы сәхифәләрендә басылачак.

"Туган ягым – яшел бишек" төбәкара укытучылар конференциясенә фәнни эшне тәкъдим итү таләпләре

Мәкаләләрнең тексты электрон вариантта кабул ителә, иске фотоларның JPEK форматында яхшы сыйфатлы **электрон күчерелмәләрен** җибәрү шарт. Мәкалә күләме 7-8 бит. Шрифт Times New Roman, 14 кегель, 1,5 интервал, бит үлчәмнәре: югары һәм түбән чикләре – 2 см; сул як – 3 см; уң як – 1,5 см. Текст башында (уң якта) авторның исем-фамилияләре, **телефон номерлары**, уку яки эшләү урыны, уртада доклад исеме языла.